ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

2018 елның 9 апреле № 162

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары төзү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 18 гыйнварындагы 22 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 1 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 2.2 пункты, 2.1 пунктының «г» һәм «д» пунктчалары нигезендә, җирле шартларны исәпкә алып, сайлаучылар өчен уңайлылыкны тәэмин итү максатларында, йортларның номерлары, телефон номерлары үзгәрү сәбәпле, тавыш бирү бүлмәләрен алыштырырга кирәклеге белән Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын төзү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 18 гыйнварындагы 22 номерлы карары (24.03.2014 ел. № 199, 25.08.2014 г. № 521 09.02.2015 ел. № 58 03.09.2015 ел. № 362 29.07.2016 ел. № 469 30.09.2016 ел. № 565 11.11.2016 ел. № 687 07.12.2017 ел. № 674 16.01.2018 ел. № 19) кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Кече Үби авылы, Үзәк урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан 1338 нче сайлау участогын һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле районы, Хайбулдин авылы, Клуб урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан 1366 нчы сайлау участогын бетерергә.

1.2. Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Яңа Үби авылы, Мир урамы, 7 йорт, адресы буенча урнашкан 1337 нче сайлау участогы чикләрен аңа 1338 нче ликвидацияләнгән сайлау участогы территориясен кушып үзгәртергә, кушымтаның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5. 1337 нче Яңа Үби сайлау участогы**

Үзәк - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Уби төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ, Яңа Үби ав., Мир ур., 7 й., тел.35-5-92.

Сайлау участогы чикләренә Яңа Үби, Кече Үби авыллары керә.
Сайлаучылар саны-722.».

1.3. Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Чуваш Чүпрәлесе авылы, мәдәният урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан 1365 номерлы сайлау участогы чикләрен аңа 1366 номерлы ликвидацияләнгән сайлау участогы территориясен кушып үзгәртергә, түбәндәге редакциядә кушымтаның 33 пунктын бәян итәргә:

**«33. <u>1365 нче номерлы Чуаш Чүпрәлесе сайлау участогы</u>**

Үзәк - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Чуаш Чүпрәле урта гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ, Чуаш Чүпрәлесе ав., Мәдәни ур., 5 йорт, тел. 37-2-34.

Сайлау участогы чикләренә Чуваш Чүпрәлесе, Хәйбулдин, Кушкуак авыллары керә.

Сайлаучылар саны-852.».

1.4. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын төзү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 18 гыйнварындагы 22 номерлы карарына кушымтаның 2, 17, 25 һәм 30 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарның 1.1-1.3 пунктчаларының үз көченә керүе 2018 елгы Россия Федерациясе Президентын сайлау кампаниясе тәмамланганчы кичектерелергә тиеш.

3. Әлеге карарны Чүпрәле районының «Туган як» газетасында бастырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитет Җитәкчесе М.Р. Гафаров